РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ӘСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Центральная, д.38Б, с. Асеево,
Азнакаевский район, 423310

Үзәк ур., 38Б нче йорт, Әсәй авылы, Азнакай
районы, 423310

Тел./факс(885592)43-2-37, 43-3-27; E-mail: Asv.Azn@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» апрель 2022 ел № 26

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 февралендәге 84-48нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында (2016 елның 30 ноябрендәге 45нче, 2017 елның 4 сентябрендәге 13нче, 2020 елның 10 мартындагы 35нче, 2021 елның 11 августындагы 31-17нче номерлы карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Әсәй авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең башкарма комитеты карар бирә:

1. Әсәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 февралендәге 84-48нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең" җирдән файдалану һәм муниципаль берәмлек төзелеше кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүгә керешергә (2016 елның 30 ноябрендәге 45нче, 2017 елның 4 сентябрендәге 13нче, 2020 елның 10 мартындагы 35нче, 2021 елның 11 августындагы 31-17нче карарлар редакциясендә):

1.1. 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 3 статьясы һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясы белән туры китерергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый http://pravo.tatarstan.ruмәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һзм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.//

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык З.Ә. Идрисов.

Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге
башкарма комитет карарына 1 нче кушымта
№26 “28” апрель 2022 ел

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүнең якынча сроклары**

| N | «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә керү турында проектны әзерләү эшләрен уздыру тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен оештыру. | 2022 елның II кварталы |
| 2.<br><br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең шәһәр төзелеше регламентларына үзгәрешләр кертү, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләрнең һәм ведомстволарның искәрмәләренә шәрехләр әзерләү. | 2022 елның II кварталы |
| 3.<br><br><br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча фикер алышу.<br>Ачык тыңлаулар үткәрү.<br>Азнакай муниципаль районы башлыгына Азнакай муниципаль районы “Әсәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге төзелешләренең җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект юлламасы Азнакай муниципаль районы “Әсәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге төзелешен раслау яисә кире кагу турында карар кабул итү өчен аңа карата мәҗбүри булган кушымталар (гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) җибәрү турында карар кабул итү өчен авыл җирлеге Советына кертү өчен җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, аны кабат тәкъдим итү датасын күрсәтеп, эшләп бетерергә җибәрергә. | III квартал 2022 ел |